**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 21 октябрь № 791

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләвен арттыру турында» 2014 ел, 18 октябрь, 768 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләвен арттыру турында» 2014 ел, 18 октябрь, 768 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендә «дәүләт учреждениеләре» сүзләреннән соң «һәм Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары» сүзләрен өстәргә;

карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Хезмәт өчен түләү шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары белән җайга салына торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары хезмәткәрләренә 2015 елның 1 октябреннән вазыйфаи окладларына, стимуллаштыру характериндагы түләүләренә (башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләрдән һәм премия түләүләреннән тыш) һәм авыл җирендә эшләгән өчен түләүләренә 10 процент күләмендә өстәмә өстәлмә билгеләргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче;

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче;

«Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләре һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче;

«Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 10 декабрь, 1072 нче;

«Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2013 ел, 31 июль, 538 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков